# Ачык дәрес

# Тема: "Табигать дусты бул!"

**ТЕМА:** "Табигать дусты бул!"

**МАКСАТ:** 1. Аз калган, бетеп бара торган үсемлекләр һәм хайваннар турындагы белемнәрне ныгыту; табигать турындагы белемнәрне тирәнәйтү, дөнья турында тулысынча күзаллау булдыру. Кеше тормышында табигатьнең әһәмиятен күрсәтү. Табигатьнең авыр хәлгә төшүенә еш кына кешеләрнең ялгыш адым ясаулары сәбәп булганын аңлату. Табигатьне саклауның якты, күркәм эш икәнлегенә төшендерү.

2. Укучыларның фикерләү сәләтен, бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Игътибарлыгын арттыру, хәтерләрен ныгыту. Балаларның табигать күренешләре белән кызыксынучанлыгын үстерү.

3. Табигатькә һәм әйләнә-тирә дөньяга сакчыл караш тәрбияләү. Табигатькә мәрхәмәтлелек хисе тәрбияләү. Матурлыкны күрә аның белән соклана белергә өйрәтү. Туган җиргә, туган як табигатенә карата мәхәббәт тәрбияләү.

**ҖИҺАЗЛАУ:** "Әйләнә-тирәбездәге дөнья" А.А.Плешаков, 2 кл., 1нче бүлек. Рәсемнәр төшерелгән плакатлар, биремнәр, табышмаклар, "Кызыл китап", дәфтәр; йолдызчыклар.

**ДӘРЕС БАРЫШЫ:**

1. **ОЕШТЫРУ МОМЕНТЫ:** Укытучы: Исәнмесез, балалар. Дәрескә бөтен әйберләрегез дә әзерме: китап-дәфтәрләрегез, ручка, карандашларыгыз бармы? Бүген без сезнең белән кызыклы сәяхәт ясарбыз. Ләкин юлга кузгалганчы, әйдәгез әле, бүгенге һава торышын тасвирлап китик. Башка көннәрдән аермалы буларак нинди үзгәрешләр күрәсез?

**УКУЧЫЛАР:** көннең числосын, атнаның көнен, ел фасылын атыйлар, һава торышы турында сөйлиләр (һава температурасы, явым-төшем, җил һ.б.).

**II. БЕЛЕМНӘРНЕ АКТУАЛЬЛӘШТЕРҮ. ӨЙ ЭШЕН ТИКШЕРҮ.**

– Ә хәзер юлга чыксак та була. Кайда сәяхәт ясаячагыбызны белер өчен тактада ясалган кроссвордны чишәргә кирәк ("Кызыл китап" дигән үткән дәрес темасын кабатлау) Кроссворд "Кызыл китап"ка нигезләнеп төзелгән. Нәрсә соң ул "Кызыл китап"? Анда нәрсә турында язылган? Ул нигә нәкъ менә кызыл төстә?

**Укучылар:** Кызыл китапта Җирдә аз калган, бетеп бара торган үсемлекләр һәм хайваннар турында белешмәләр тупланган. Аның тышлыгының кызыл төстә булуы табигатькә куркыныч янавы турында кисәтә.

**Укытучы:**

– Дөрес. Ә хәзер кроссвордны чишик.

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 1. | З | У | Б | Р | | | | | |
| | | | | | | 2. | Т | Ө | Н | Б | О | Е | К | |
| | | | 3. | Т | У | К | Р | А | Н | | | | | |
| | | | | | 4. | Б | А | Ш | М | А | К | Ч | Ы | К |
| 5. К | Ы | Ң | Г | Ы | Р | А | У | | | | | | | |

1. Бу хайван урманда яши. Аны "кыргый үгез" дип тә атыйлар. Олы һәм авыр гәүдәле. Юкка чыга баруының сәбәбе – урманнарны кисү, аучылык, браконьерлык.

2.Бу үсемлек күлләрдә, сулыкларда үсә. Зур яфраклары һәм ак төстәге эре чәчәкләре су өстендә йөзеп йөри, ә юан тамыры – су астында урнашкан. Аның әзәюе елгаларның саегуы һәм пычрануына бәйле.

II

3. Бу кош урманда яши. Агач куышында оялый, бөҗәкләр белән туклана. Аны "урман табибы" дип тә атыйлар. Саны урманнарны кисү нәтиҗәсендә әзәя.

4. Бу үсемлекнең чәчәк төзелеше кечкенә башмакны хәтерләтә. 15-17 нче яшендә генә чәчәк ата. Юкка чыгу сәбәбе – бик матур декоратив чәчәк буларак, кешеләр тарафыннан өзелә, бакчада үстерү өчен казып алына.

5. Болыннарда һәм кырларда үсә торган зәңгәр чәчәкле үсемлек. Аның атамасы чыңлау белән бәйле. Көтүлекләр һәм сөрү җирләрен арттыру сәбәпле азая.

Укытучы:

– Балалар, без сезнең белән кыскача гына үткән теманы кабатладык. Ә хәзер, әйдәгез, нәтиҗә ясыйк.

Укучылар: Үсемлекләр һәм хайваннарны сакларга кирәк. Табигатьтәге бөтен әйбер дә бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән. Кешеләрнең табигатькә саксыз карашы үсемлекләрнең һәм хайваннарның азаюының, хәтта юкка чыгуының төп сәбәбе булып тора. "Кызыл китап" кешеләрне шул турыда кисәтә, табигатьне сакларга кирәклеген искәртә.

III. ЯҢА ТЕМА ӨЙРӘНҮ.

Укытучы: Дөрес, кеше табигать белән тыгыз бәйләнештә тора һәм аңа турыдан – туры тәэсир итә. Кызганычка каршы, үсемлекләргә һәм хайваннарга бу күп очракта зыян гына китерә. Ә аларсыз җир шарындагы тормышны күз алдына да китереп булмый. Шуңа күрә табигатьне сакларга, аның әкренләп үлә баруын туктатырга кирәк. Бүгенге дәрес тә шул турыда – ул "Табигать дусты бул!" дип атала. Сәяхәтебез дә аңа багышланган.

Шулай итеп, кроссвордның кызыл белән бүленгән өлешендә "Утрау" сүзе килеп чыкты. Без сезнең белән утрауларга сәяхәт итәчәкбез, сез "Соңгы герой" уенында катнашачаксыз.

Укучылар ике командага бүленәләр: берсе Яшел утрауда, икенчесе Чәчәкле утрауда урнаша.

Укытучы: Утрауларга йөзәр өчен сезгә көймәләрне төзәтергә кирәк. (Тактага 2 көймә рәсеме эленә). Ике көймәнең дә төбе тишелгән, аларны ямарга кирәк. Моның өчен уенчылар кәгазьдән киселгән түгәрәк "ямауда" язылган биремне үтәргә тиеш. Дөрес җавап биргән команда тишекне түгәрәк белән каплый. (Биремне дөрес эшләп чыккан командага йолдыз бирелә).

"Арыслан" командасына табышмак:

Чит-чите – таллык,<br>
Уртасы – сазлык,<br>
Керсәң – батарсың<br>
Чыгалмый ятарсың.<br>
(Күл).

"Барс" командасына табышмак:

Ага-ага, агып бетәлми,<br>
Чаба-чаба, чабып җитәлми.<br>
(Елга).

УКЫТУЧЫ: Су безгә тереклек өчен, яшәр өчен кирәк. Ләкин хәзер чишмәләрне елгаларны завод һәм фабрикалар пычрата, балыклар һәм башка җан ияләре үлә. Яр буендагы үсемлекләр корый. Без мондый елгаларда, күлләрдә су коена алмыйбыз. Елга төбендә консерв банкалары, пыяла ватыклары, тимер кисәкләре ята. Ә кайвакытта

без үзебез дә суны саклап тота белмибез. Никадәр су әрәмгә китә! Шуңа күрә суны-табигать күркен сакларга кирәк. Моның өчен нишләргә кирәк, балалар?

**Укучылар:** – Сулыкларга чүп ыргытмаска, чишмәләрне чистартып торырга, елгаларда, күлләрдә яшәүче хайваннар, алар кырыенда үсүче үсемлекләргә зыян салмаска кирәк.

**УКЫТУЧЫ:** Дөрес. Балалар, әйдәгез бу елгага "Сулыкларны пычратмагыз" дигән билге куйык. Үткән елның җәй айларында безнең мәктәп каршында экологик лагерь эшләде. Безнең сыйныф укучылары да бу лагерьда булдылар, шулай бит? Әйдәгез әле, балалар, анда нәрсә эшләгәнегез турында сөйләп китегез.

**Укучылар:** Безнең экологик лагерьнең исеме "Хәзинәләр" утравы дип атала иде. 16 кешедән торган безнең "Ак төнбоек" кабиләсе "Суүсемнәр һәм елга буе үсемлекләренең экологиясе" дигән тема өстендә эшләде. Иң элек без әлеге темага кагылышлы материал тупладык ("Кызыл китап", газета-журналлар, үсемлекләр турында белешмәләр һ.б.). "Зур күл", "Шөгермәк", "Наратлы" күлләренә сәяхәт ясадык. Авылыбыз янында урнашкан чишмәләргә ("Изге Чишмә", "Тарлау чишмәләре", "Миннәхмәт чишмәсе", "Таза чишмә") экскурсиягә бардык. Әлеге сулыкларда, алар кырыенда үсүче үсемлекләрне күзәттек, күзәтүләрне язып бардык, рәсемгә, фотога төшердек. Чишмәләрне чистартуда, ясалма сулык ясауда катнаштык. Яр Чаллы шәһәренең экологик музеена экскурсиягә бардык.

**УКЫТУЧЫ:** Бу утрауларның табигатенә куркыныч яный: әкренләп хайваннар юкка чыга, үсемлекләр кибә. Монда сез үзегез өчен генә түгел, ә утрауның яшәве өчен дә көрәшергә тиеш буласыз.

Барлык тереклек өчен дә һава кирәк. Без яшел үсемлекләр бүлеп чыгарган кислородны сулыйбыз. Алар шулай ук кеше һәм хайваннар өчен азык чыганагы булып торалар. Кошлар үсемлекләргә зарар китерүче бөҗәкләрне юк итәләр, агачларның, куакларның орлыкларын тараталар. Ягъни, табигатьнең һәрбер компоненты бер-берсе белән бәйле. Һәм бу бәйләнештә бер генә үзгәреш тә, бигрәк тә кире якка, аларның юкка чыгуына китерә. Монда аеруча кешенең катнашы сизелә.

**2 НЧЕ БИРЕМ: "АГАЧЛАР УТЫРТ!"**

Утраудагы киселгән агачлар урынына яңаларын утыртырга кирәк. Укучыларга агач исемнәре язылган кәгазьләр таратыла. Ике команда уенчылары да 1 нче рәткә – ылыслы, 2 – яфраклы агачлар, 3-нче рәткә – куаклар урнаштырырга тиеш. (Чыршы, нарат, кедр, каен, имән, юкә, усак, балан, кура җиләге, акация, чикләвек). Биремне дөрес һәм тиз эшләү бәяләнә. Җиңүче командага йолдыз бирелә.

**УКЫТУЧЫ:** Урманнар – җир шарының яшел хәзинәсе. Чөнки агачлар тереклекне кислород белән иң төп тәэмин итүчесе булып торалар. Алар шулай ук күп кенә хайваннарның һәм кошларның өе дә. Урман безгә чиста һава, җиләк, чикләвек, гөмбәләрен бүләк итә, анда күп кенә дару үсемлекләре дә үсә. Агачтан кеше төрле әйберләр ясый, өйләр төзи. Шуңа күрә без агачларны, урманнарны сакларга тиеш: аларны сындырмаска, кисмәскә кирәк. Урманда үскән үсемлекләрне, чәчәкләрне таптамаска, өзмәскә кирәк. Чүп ыргытырга, учак ягарга, урманда яшәүче җәнлекләрне куркытырга, аларга тияргә ярамый. Әйдәгез әле, монда да "Урманнарны саклагыз" дигән билге куйык!

**ФИЗКУЛЬТМИНУТКА:**

Ишкәк ишә ишкәкче
Иделләргә җитмәкче
Агым суга каршы барып

IV

Дулкыннарны кисмәкче
Кояш елмая күктә,
Су өсте җем-җем килә.
Ишкәк ишү, суда йөзү
Беләкне көчле итә.

3 НЧЕ БИРЕМ: "ЧӘЧӘКЛӘРНЕ КОТКАР"

УКЫТУЧЫ: Балалар, карагыз әле, болындагы чәчәкләр шиңеп беткәннәр. Әйдәгез әле, аларны терелтик.

Плакатка чәчәкләр төшерелгән, аларның берничә таҗы юк. Укучыларга биремнәр язылган таҗлар таратыла. Дөрес эшләгән очракта таҗ урынына куела.

1 нче командага: Яраны төзәтер өчен нинди үсемлекләр кулланырга була (бака яфрагы, көтүче сумкасы).

2 нче командага: Суык тиюдән нинди дару үләннәре ярдәм итә (кура җиләге, юкә чәчәге, мәтрүшкә).

4 НЧЕ БИРЕМ: "КҮБӘЛӘКЛӘРНЕ КОТКАР"

Плакатка күбәләкләр төшерелгән. Алар сөкәгә эләккәннәр (марля белән капланган). Биремне дөрес итеп үтәгән команда күбәләкне коткара.

1 НЧЕ КОМАНДАГА:
Үзе бәләкәй булса да,
Үзеннән зур күтәрә,
(Кырмыска).

2 нче командага:
Җәйнең буе бал җыя
Кышның буе хәл җыя.
(Бал корты).

Укытучы "Хайваннарны һәм үсемлекләрне сакларга" дигән билге куя.

ДӘРЕСЛЕК БЕЛӘН ЭШ

УКЫТУЧЫ: Китапның 86 нчы битен ачтык: сорауны укып рәсем буенча җавап бирү.

87 бит буенча уку: экологик кагыйдәләр белән танышу; Нәтиҗә ясау: табигатьне ничек сакларга? (укучылар җавабы).

IV. ЙОМГАКЛАУ.

УКЫТУЧЫ: Укучылар, кеше тормышында табигать нинди роль уйный? Кеше табигатькә ничек тәэсир итә? Табигатьне саклау өчен нишләргә кирәк?

УКУЧЫЛАР (йомгак ясыйлар). Кеше һәм табигать үзара тыгыз бәйләнештә торалар. Табигатьтән кеше азык, су, чиста һава, төзелеш материаллары ала. Табигать – хайваннарның һәм кошларның өе. Кеше табигатькә күбесенчә кире тәэсир ясый: сулыкларны, һаваны пычрата, урманнарны юкка чыгара, һ.б. Табигать әкренләп үлә. Моны булдырмас өчен кеше табигать дусты булырга тиеш: аны якларга, сакларга тиеш.

УКЫТУЧЫ: Шигырь укый.

– Бүгенге уенда ике команда да җиңүче булды – чөнки алар утрауларның табигатен саклап калдылар.

Молодцы!

V. ӨЙ ЭШЕ. 86-87 нче битләр. Укырга, сорауларга җавап бирергә. Дәфтәргә дәреслектә булмаган экологик тамга уйлап чыгарып ясарга.